КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 31 май г.Казань № 414

Оешмаларның Татарстан Республикасы дәүләт телләрендәге социаль әһәмиятле әдәбиятны электрон һәм басма төрдә матбугатка әзерләү, бастырып чыгару һәм тарату чыгымнарын каплау өчен Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидияләр бирү тәртибен раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән Татарстан Республикасы дәүләт телләрендәге социаль әһәмиятле әдәбиятны электрон һәм басма төрдә матбугатка, бастырып чыгаруга әзерләү һәм тарату буенча оешмалар чыгымнарын каплау өчен Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидияләр бирү тәртибен расларга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының түбәндәге карарлары үз көчен югалткан дип танырга:

«Оешмаларның социаль әһәмиятле әдәбиятны басмага әзерләү, бастырып чыгару һәм тарату чыгымнарын каплау өчен Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2016 ел, 21 июнь, 421 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Оешмаларның социаль әһәмиятле әдәбиятны басмага әзерләү, бастырып чыгару һәм тарату чыгымнарын каплау өчен Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2016 ел, 21 июнь, 421 нче карары белән расланган Оешмаларның социаль әһәмиятле әдәбиятны басмага әзерләү, бастырып чыгару һәм тарату чыгымнарын каплау өчен Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбен-

нән субсидияләр бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында» 2017 ел, 29 декабрь, 1122 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Оешмаларның социаль әһәмиятле әдәбиятны басмага әзерләү, бастырып чыгару һәм тарату чыгымнарын каплау өчен Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2016 ел, 21 июнь, 421 нче карары белән расланган Оешмаларның социаль әһәмиятле әдәбиятны басмага әзерләү, бастырып чыгару һәм тарату чыгымнарын каплау өчен Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидияләр бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында» 2018 ел, 21 ноябрь, 1025 нче.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин